Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

25.07.2025 №14

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 23 сентябрендәге 23 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 05 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2021 елның 23 сентябрендәге 23 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1.2 өлешнең унынчы абзацында «әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гаризасы белән» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 2.3 өлешнең 2.3.2 пунктында «берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә» сүзенә алмаштырырга;

1.3. 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару турында Карар кабул итү, адреслашу объектына адрес бирүдән баш тарту яисә аның адресын юкка чыгару турында карарлар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле белешмәләрне дәүләт адреслар реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

а) гариза кәгазьдә бирелгән очракта-гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта - гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.».

2. Әлеге карарны ТР Спас муниципаль районының рәсми сайтында рәсми рәвештә http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә.

Чәчәкле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Фәисханов